**20. Казан**

Куп милләтләр белән туганлашып,
Бердән булып яши халкыбыз,
Үрләр яулап, үсә халкыбыз,
Үсә Казан - туган йортыбыз.
Биек йортлар калка монда
Саклый халкым, саклый тарихын.
И, Казаным! Татар халкы өчен
Син бит мәгърүр, гүзәл башкала.
Кушымта: Казан! Казан!
Кол Шәрифтән яңгырый азан,
Туганлашып яши синең халкың, Казан.
Казан! Казан!
Данлый сине халкым, Казан.
Уем, җырым, синең хакта - Казан!
Зур өметләр баглап килә яшьләр,
Яңа алмаш үсә - балалар,
Кыйбла итеп, синнән урнәк ала,
Зур бистәләр, олы калалар.
Чит җирләрдә купме йөрсәк тә.
Куңел һаман сиңа тартыла.
Син бит, Казан, татар халкы өчен
Бердәнбер гүзәл башкала.